**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «16» маеннан № 142

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 2011 елның 01 ноябрендәге 424 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 маендагы 300 номерлы номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 2011 елның 01 ноябрендәге 424 номерлы карарына (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 15 декабрендәге 593 номерлы, 2013 елның 21 октябрендәге 4367 номерлы; 2014 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы; 2015 елның 02 ноябрендәге 306 номерлы; 2016 елның 06 июлендәге 263 номерлы; 2017 елның 08 августындагы 390; 2018 елның 16 гыйнварындагы 11; 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2023 елның 02 февралендәге

29 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2011 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2014 елның 1 июленнән» сүзләренә алмаштырырга.

Күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (беркетелә).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «16» маеннан 142
номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0126 | 19 484 |
| 3 | 1,0256 | 19 735 |
| 4 | 1,0381 | 19 975 |
| 5 | 1,0521 | 20 245 |
| 6 | 1,0656 | 20 504 |
| 7 | 1,0802 | 20 785 |
| 8 | 1,0942 | 21 055 |
| 9 | 1,1083 | 21 326 |
| 10 | 1,1233 | 21 615 |
| 11 | 1,1379 | 21 895 |
| 12 | 1,1535 | 22 196 |
| 13 | 1,1691 | 22 496 |
| 14 | 1,1846 | 22 794 |
| 15 | 1,2008 | 23 106 |
| 16 | 1,2174 | 23 425 |
| 17 | 1,2340 | 23 745 |
| 18 | 1,2512 | 24 076 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладына) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.